**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Село Янурусово, улица Ленина, дом 43а,
423370 Телефон 4-10-19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ**

Ленин урамы,43 а йорт, Янурыс авылы,
423370 Телефон: 4-10-19

ОГРН 1031604000757 ИНН/КПП 1636001403/163601001 ОКАТО 92253884000

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
№15 14.12.2020

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы (ред. 13.03.2020) Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Янурыс авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымта «Сарман муниципаль районы «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү турында нигезләмәгә» түбәндәге эчтәлекле 6,7,8 пунктлар өстәргә:

«6. Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затның еллык түләүле отпуск төп түләүле отпусктан һәм өстәмә түләүле отпусктан тора.

7. Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затлар өчен ел саен түләнә торган төп түләүле отпуск дәвамлылыгы муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә, ләкин 30 календарь көннән дә ким булмаска тиеш.

8. Тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгы муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затка муниципаль вазыйфаны биләгән һәр ел өчен календарь көн, муниципаль хезмәт вазыйфасын, шулай ук дәүләт вазыйфасын һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән өчен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә. Еллык төп түләүле отпускның һәм муниципаль вазыйфаны

даими нигездә биләүче зат өчен, тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның гомуми дәвамлылыгы 45 календарь көннән арта алмый.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы

Янурыс авыл җирлеге башлыгы А. Ә. Мөхәммәдиева